МИНБӘР
Байлык та сынау, фәкыйрьлек тә...
→ 4 БИТ

СОРАУ-ҖАВАП
Гипслы вакытта тәһарәт алу
→ 7 БИТ

ТАРИХ
Зәйсән – татар халкының югалган тарихы
→ 11 БИТ

ТӘРБИЯ
Әнием дәресләре
→ 13 БИТ

**МАЙ, 2023**
№ 05 (334)

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте басмасы

ШӘҮВӘЛ-ЗӨЛКАГЪДӘ, 1444

# ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

12+


Фото: shutterstock.com

**Дөньяның гаять матурлыгы, барлык нигъмәтләрнең булуы Аллаһының рәхмәтедер. Шулай ук динебез дә безгә карата Аллаһының рәхмәте ул. Аллаһы Тәгалә безне хаклыкны аңлап, иман китереп, изге гамәлләр кылып, югары әхлаклы булып яшәүгә, дөнья һәм Ахирәттә бәхетле булуга чакыра. Коръән укый башлаганда да Аллаһының Рәхимле һәм Шәфкатьле дигән бөек исемнәре белән башлыйбыз...**

**ДӘВАМЫ → 6 НЧЫ БИТТӘ**

ГАЗЕТАДА АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘНЕҢ ИСЕМНӘРЕ, КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ БУЛГАНЛЫКТАН, БАСМАГА ИГЪТИБАРЛЫ БУЛЫГЫЗ!

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 05 (334) май, 2023 | шәүвәл-зөлкагъдә, 1444

# УРЫССУДА РОССИЯКҮЛӘМ КОРЪӘН БӘЙГЕСЕ УЗДЫ

14 нче майда Ютазы районы Урыссу бистәсендә хатын-кызлар арасында «Халисә» IV Россиякүләм Коръән укучылар бәйгесе үткәрелде. Әлеге конкурс һәр елдагыча Татарстан мөфтияте, Татарстанның көньяк-көнчыгыш төбәге казыяте, Ютазы мөхтәсибәте тарафыннан




Фото: dumrt.ru

Ютазы районы хакимияте һәм Мәрданшиннар гаиләсе ярдәме белән оештырылды.

Бәйгенең беренче көнендә 60 катнашучы сайлап алу турында көч сынашты. Алдагы көнне исә иртәдән Урыссу бистәсе Мәдәният йортында финалга чыккан 28 кыз 4 номинация буенча ярышты.

Һәр номинациядә 7шәр катнашучы үз белемнәрен сынады, түбәндәге номинацияләр буенча мәртәбәле жюри каршында имтихан тотты:

1. Коръәннең 3 (28–30) җөзен яттан белү.
2. Коръәннең 5 (26–30) җөзен яттан белү.
3. Коръәннең 7 (24–30) җөзен яттан белү.
4. Коръәнне тулысынча яттан белү.

Быел катнашучыларның географиясе киңәйде, Татарстан һәм күрше Башкортстан район-шәһәрләреннән тыш, хатын-кызлар шулай ук Уфа, Магнитогорск, Чиләбе шәһәрләреннән, Мәскәү һәм Пенза өлкәләреннән килде. Катнашучылар һәм аларны озата килүчеләр бушлай туклану һәм кунакханә белән тәэмин ителде. Иң яшь катнашучыга – 8, иң олысына – 38 яшь иде.

Конкурсның тантаналы ачылышында барлык катнашучыларны Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, Татарстанның көньяк-көнчыгыш төбәге казые, Ютазы районы имам-мөхтәсибе Марат хәзрәт Мәрданшин, Ютазы муниципаль районы башлыгы, Ютазы район Советы рәисе Аяз Шәфигуллин, Болгар ислам академиясе мөгаллиме, Ислам фәннәре докторы, Коръән-хафиз Сәиф Әли Әл-Асри сәламләде. Чыгыш ясаучылар «Сезнең арагызда иң яхшыгыз – Коръәнне өйрәнүчеләр һәм аны башкаларга өйрәтүчеләр» дигән хәдисне искә төшерде, Коръәннең бөек китап булуын ассызыклап узды.

Ун кыйраәт буенча иҗазәткә ия Кәүкәб Әл-Асри, Коръән ятлау үзәге мөгаллимәләре Әлфия Зиннәтуллина, Лена Закирова, Фирүзә Абдуллаева жюри буларак үз бәяләрен бирделәр һәм җиңүчеләрне ачыкладылар.

«Коръәнне тулысынча яттан белү» номинациясенә Тукай муниципаль районы «Күзкәй урта гомуми белем бирү мәктәбе» гомуми белем бирү укучысы 16 яшьлек Айсылу Хаҗиева лаек булды һәм ул гомрәгә юллама белән бүләкләнде. Номинациянең 2нче урынына Гөлрухсор Сәфәрова («Мөхәммәдия» мәдрәсәсе), 3нче урынына Наилә Әминова (Уфа) лаек булдылар.

Башка номинацияләрдә җиңүчеләр:

1. Коръәннең 3 (28–30) җөзен яттан белү: 1нче урын – Аиша Кушматова (Әлмәт ислам мәдрәсәсе); 2нче урын – Жамира Мирзоева (Башкортстан); 3нче урын – Омина Мирадилжанова (Урыссу «Фәнис» мәдрәсәсе).
2. Коръәннең 5 (26–30) җөзен яттан белү: 1нче урын – Вера Кәримова (Чаллы); 2нче урын – Зәйнәб Хәйретдинова (Түбән Кама); 3нче урын – Мәрьям Шакирова («Мөхәммәдия» мәдрәсәсе).
3. Коръәннең 7 (24–30) җөзен яттан белү: 1нче урын – Әминә Вәлиуллина (Уфа); 2нче урын – Әминә Хәнҗәрова (Әлмәт ислам мәдрәсәсе); 3нче урын – Хәдичә Маликова (Казан).

7 җөзне яттан белү номинациясендә беренче урын алучы – 50 мең, 5 җөзне иң яхшы белүче – ноутбук, 3 җөздә җиңү яулаучы – 30 мең күләмендә акчалата бүләккә ия булды.

Татарстанның көньяк-көнчыгыш төбәге казые, Ютазы районы имам-мөхтәсибе, Урыссуның «Фәнис» мәдрәсәсе җитәкчесе, тарих фәннәре кандидаты Марат хәзрәт Мәрданшинның башлангычы һәм тырышлыгы белән үткәрелгән Коръән бәйгесе аның әнисе хөрмәтенә «Халисә» дип исемләнде. Бәйге 2020 елдан алып, һәр елны Урыссу бистәсендә үткәрелә. Аны оештыруда Халисә апаның 5 баласы җиң сызганып катнаша һәм үз өлешен кертә.

**dumrt.ru** сайтыннан

# ТАТАР ДИН ӘҺЕЛЛӘРЕ ФОРУМЫНЫҢ ПЛЕНАР УТЫРЫШЫ УЗДЫ




Фото: dumrt.ru

## МӨФТИ — ТАТАР ДИН ӘҺЕЛЛӘРЕ ФОРУМЫНДА: «ДИНИ ХЕЗМӘТЛӘРНЕ ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ЯЗАРГА ҺӘМ БАСТЫРЫРГА ТӘКЪДИМ ИТӘМ»

20 нче май көнне, Казанда Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов катнашында «Милли тормыш һәм дин» XIII Бөтенроссия татар дин әһелләре форумының пленар утырышы үтте. Форумга Россия Федерациясенең 77 регионыннан, шул исәптән Татарстан Республикасыннан барлыгы 1000 дин әһеле һәм кунак килде. Пленар утырышта хөкүмәт әгъзалары, ТР Дәүләт Советы депутатлары, Бөтендөнья Татарстан конгрессының Милли шура әгъзалары һ.б. катнашты.

Һәр елдагыча, форум катнашучылары дин өлкәсенә кагылышлы мөһим сораулар һәм мәсьәләләр буенча фикер алышу өчен җыелды, делегатлар өчен бай эчтәлекле программа әзерләнде.

Пленар утырышны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев алып барды. Ул татар халкында бәйрәмнәр генә түгел, Аллаһы Тәгалә тарафыннан сынау итеп җибәрелгән афәтләр, кайгылар да бердәмлекне ныгыта дип, 6нчы майда Омск өлкәсендәге Каракүл авылы, 8нче майда Курган өлкәсенең Йолдыз татар авылында чыккан янгыннарда милләттәшләр күрсәткән гуманитар ярдәмне телгә алды.

Алга таба сүз мөфтиләргә бирелде. Россия Мөфтиләр шурасы рәисе, РФ мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе Равил хәзрәт Гайнетдин эшчәнлек, тәҗрибә, планнары белән бүлеште, Казанда шушы көннәрдә үткән фәнни җыен нәтиҗәләренә тукталды, былтыр Россиядә Идел буе Болгар дәүләтендә Исламны кабул итүнең 1100-еллыгын билгеләп үтүнең тәэсирләре белән уртаклашты.

Көнүзәк мәсьәләләр турында сөйләшүне алга таба Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин дәвам итте. Ул 2022 елның вакыйгаларга бай булуын искәртте һәм Россия өммәте өчен күбрәк уңай үзгәрешләрне санап китте: 1100-еллыкны билгеләп үтү, Ислам финансларын кертеп җибәрү өчен эксперимент эшли башлау, тукталып торганнан соң хаҗ кылырга мөмкинлек ачылу, Мәскәүдә мәчет салу өчен урын бүлеп бирелү, Казанда, Уфада һәм Мәскәүдә иң эре мөселман уку йортлары өчен яңа корпуслар төзелү… Шул ук вакытта Камил хәзрәт җәмәгатьнең игътибарын күңелсез хәлләргә дә юнәлтте. Мисал итеп ул Кургандагы янып беткән Эчкен авылын китерде, шулай ук «Сахих Әл-Бохари»ның бер тәрҗемәсе тыелуны атады. Соңгысы уңай хәл ителсә дә, мөфти шуңа охшаш ситуация тагын килеп чыкмас, дип беркем ышандыра алмавын кисәтте:

– Бу вакыйгадан Россия мөселманнарына үзләре өчен дөрес нәтиҗәләр чыгарырга кирәк, ул, һичшиксез, безгә сабак булырга тиеш. Ни өчен дигәндә, чөнки проблеманың төбендә судларның гаделсез карарлары түгел. Проблеманың асылы – мөселман китапларына дини-фәнни анализ урынына психологик-лингвистик анализ ясалу. Китапларның текстларын экстремистик дип шуның нигезендә таныйлар. Ягъни Россиядә дини әдәбиятка экспертизаны тиешле әзерлеге булмаган белгечләр ясый. Югыйсә, басылып чыкканчыга кадәр, китап мөселман-дини экспертиза аша үтсә, күп сораулар үзеннән үзе хәл ителер иде, – дип аңлатып үтте ул.

Камил хәзрәт мәсьәләгә чишелеш тә тәкъдим итте: шуның беренчесе – татар дин әһелләренә дини хезмәтләрне татар телендә язу һәм бастыру: «Татарча язылган дини әдәбиятның тыелганы юк. Шул ук вакытта татар дини-илаһияткә, татарча китаплар базары үсеше өчен дә саллы өлеш кертелер иде».

Камил хәзрәтнең тагын бер тәкъдимен дә яңгыратты:

– Һичшиксез, бүген безгә дини әдәбиятны тикшерү өчен Россиякүләм дини экспертлар оешмасы кирәк. Ул мөселман басмаларының язмышын судка кадәр дә, суд эше барган вакытта да хәл итәргә ярдәм итә алыр иде. Экспертлар шурасы шул ук вакытта көн кадагындагы мәсьәләләрне берәмберәм түгел, ә җыелып, уртак көч белән чишә алыр иде. Алар күп: мәктәп һәм бакчаларда хәләл туклану, мәчет-мәдрәсәләрнең җитмәве, хиҗабны тыю һ.б. Хәзер менә дини әдәбиятны судларда тыю проблемасы килеп басты.

Мөфти хәзрәт шулай ук татар дин әһелләренә Татарстан мөфтияте һәм «Хозур» нәшрияты ярдәмен дә тәкъдим итте: «Татарстан Диния нәзарәтенең уңай тәҗрибәсе бар - бездә экспертлар шурасы эшли, ул китапларны дөньяга чыгарганчы тикшерә, шул рәвешле басмаларны тыюдан үзенә күрә бер саклык чарасы күрелә», – дип җиткерде Камил хәзрәт һәм Диния нәзарәтенең фундаменталь басмаларны башка мөфтиятләр белән хезмәттәшлектә чыгару тәҗрибәсе белән дә уртаклашты. Билгеле булганча, «Сахих аль-Бухари» в версии «Зубдат» китабын һәм «Калям Шариф. Перевод смыслов» хезмәтен Татарстан мөфтияте Дагыстан мөфтияте белән бергә әзерләп бастырды.

Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Нургали улы Миңнеханов катнашучыларны терәк һәм киләчәк дип атап, дин әһелләрен бердәм булырга өндәде: бергә телне, гореф-гадәтләрне, динне сакларга, үсеп килүче буынны тәрбияләргә, мәдрәсәләр ачарга һәм традицион булмаган кыйммәтләр белән бергәләп көрәшергә. Татарстан Рәисе Россия җитәкчелегенә Ислам динен үстерүгә ярдәм итә торган чаралар үткәрүгә ярдәм иткәне өчен рәхмәтен белдерде.

Пленар утырыш ахырында дини оешма җитәкчеләренә һәм дин әһелләренә дәүләт бүләкләре тапшырылды.

**dumrt.ru** сайтыннан

# БАЙЛЫК ТА СЫНАУ, ФӘКЫЙРЬЛЕК ТӘ...



Фото: shutterstock.com

**Байлык – мактану, ә ярлылык кимсенү өчен сәбәп түгел. Бу сыйфатлар кешенең ихтыяры һәм эш-гамәлләре белән бәйләнгән.**

Көчле һәм көчсез, сәламәт һәм авыру, акыллы һәм ахмак, бай һәм ярлылар арасында аерманың булуы җәмгыятьтә төзеклек һәм тәртип сакларга ярдәм итә. Байлык һәм ярлылык та бер-берсенә капма-каршы булган ике икътисади баскыч булып тора. Хакыйкатьтә, кеше тормышына сынау максатыннан бирелгән байлык һәм ярлылык халәтендә тирән хикмәт бар. Мәсәлән, байлык – мактану, ә ярлылык кимсенү өчен сәбәп түгел. Бу сыйфатлар кешенең ихтыяры һәм эш-гамәлләре белән бәйләнгән. Кешенең бай яки ярлы булуы аның тәкъдирендә, Аллаһы Тәгаләнең хикмәте белән, ул туганчы үк билгеләп куелган.

## ЗӘКЯТ – МИЛЕКНЕ ЧИСТАРТА ТОРГАН ГАМӘЛ

Матди яктан хәлле кешегә зәкят түләү бурычы йөкләнә. Гарәп теленнән, зәкят – «чистарыну», чисталык» дигәнне аңлата. Ягъни, зәкят – ул милекне чистарта торган гамәл. Бирелергә тиешле булган зәкятне бирмәү – башкаларның малын алуга тиң. Аллаһы зәкят итеп бирелергә тиешле мөлкәтнең һәр төрендә билгеле бер өлеш куйды. Шуңа күрә билгеләнгән дәрәҗәдән (нисабтан) артып киткән мөлкәттән зәкят түләве таләп ителә.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

---

*«**Аллаһы ризык аша бирәүләрегезне икенчеләрегездән өстен кылды** [бай һәм фәкыйрь итте]. **Өстен булган** [бай һәм җитәкче урыннардагы] **ул кешеләр,** [кул астындагылар] **үзләренә тигез булмасыннар дип, уң куллары ия булган** [коллар һәм эшчеләр урынындагы] **кешеләргә ризыкларын бирмиләр. Әллә алар Аллаһының** [үзләренә бирелгән моның кадәр] **нигъмәтен инкяр итәләрме?»***

*«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:71*

---

Аллаһы Тәгалә бер генә кешене дә башкаларга тиңдәш итеп куймаган, барысына да тигез итеп ризык та бирмәгән. Киресенчә, Ул бирәүләргә өстенлек биргән һәм аларга төрле дәрәҗәләр билгеләгән. Кешеләрне матди яктан тигезләү дөнья тәртибен бозуга китерер иде.

## БӨТЕН ЭШ НИЯТЕ БЕЛӘН БӘЯЛӘНӘ

Моннан тыш, Аллаһы кешеләрне физик һәм акыл сәләтләре ягыннан төрлечә итеп яратты. Шулай ук шәхси сәләтләре сәбәпле бай була алган кешеләр бар. Барысы да кешенең үзенә насыйп булган өлешенә ни рәвешле мөгамәлә итүенә бәйле булачак – ул байлыгы белән юмартлык күрсәтерме яки, ярлы булса, сабыр булырмы. Фәкыйрьлек тә бозыклык түгел һәм байлык та гөнаһ түгел, әмма бөтен эш, чын мәгънәсендә, нияте белән бәяләнә.

Бүгенге көн кешесе байлыкка омтылып, үзендәге барлык кешелек сыйфатларын югалта бара. Гадилеген генә түгел, мөлкәт җыям дип, намусын да сата, золымлык кылып, үзенә тиеш булмаганын көчсезләрдән тартып та ала. Байлыктан башны югалтмыйча кеше булып кала алу бик зур түземлек сорый. Моны, кызганыч, барыбыз да булдыра алмый.

## МӘҢГЕЛЕК БӘХЕТНЕ ДӨНЬЯ БАЙЛЫГЫНА АЛЫШТЫРУ

Риваятьләрдә килгәнчә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм вакытында Сәгъләбә исемле бер кеше яшәгән. Бу кеше акча ярата иде һәм бик бай булырга теләде. Шуңа күрә ул Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән Аллаһыга бу хакта дога кылуын сорады. Ләкин Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аны кисәтеп: «Синең өчен байлыкның аз булуы күп булуыннан яхшырак», – диде. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бу сүзләреннән соң Сәгъләбә үз фикерен үзгәртте, ләкин тиздән аның теләге яңадан көч алды һәм ул кабат, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына килеп, дога кылуын үтенде.

Аңа Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Мин сиңа үрнәк буларак җитмимме? Аллаһы Тәгалә белән ант итәм, әгәр теләсәм, бу таулар алтын-көмешкә әйләнеп, миңа иярерләр иде, ләкин мин тыелам», – диде.

Бу юлы Сәгъләбә үз фикерен үзгәртте, ләкин күңелендәге теләкләрен җиңә алмыйча: «Әгәр мин бай булсам, ярлыларга булышырмын, тагын да күбрәк изгелек кылырмын!» – дип уйлап, өченче тапкыр Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына китте. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына килеп җитеп: «Сине чын хәбәрче итеп җибәрүче белән ант итәм, бай булсам, мин ярлылар

турында кайгыртып, һәркемгә тиешлесен бирермен!» – диде.

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу юлы аның үтенечен тыңлады һәм дога кылып, Аллаһы Тәгаләгә: «Әй, Аллаһым, Сәгъләбәгә дөньяда теләгәнен бир!» – дип мөрәҗәгать итте.

Озакламый Аллаһы Тәгалә Сәгъләбәгә зур байлык җибәрде. Аның көтүләре барлык тауларны, үзәннәрне тутырды. Ләкин элек «мәчет кошы» кушаматы булган Сәгъләбә бөтен намазларны җәмәгать белән укыса, хәзер җәмәгать намазларына килүдән туктады, бары тик җомга көннәрендә генә күренә башлады. Аннары җомга намазларын да калдыра торган булды.

Көннәрдән бер көнне Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Сәгъләбә турында сорады, аңа: «Сәгъләбә юкка чыкты!» – дип җавап бирделәр.

Сәгъләбәнең ваемсызлыгы моның белән генә чикләнмәде. Зәкят җыючылар аның янына килгәч, ул ачуы белән: «Хакыйкатьтә, бу салым түләү!» – диде, үзенең вәгъдәләрен генә түгел, ә мөлкәтендә булган мохтаҗларның өлешен дә онытты.

Вакытлы дөнья байлыгы белән алданган Сәгъләбә мәңгелек дөньяда хәерче булып калды. Үлем мизгеле килеп җиткәндә, ул үкенү хисе белән Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Синең Аллаһыга шөкер итә алырлык кечкенә байлыгың Аллаһыга шөкер итә алмаган зур байлыгыңнан яхшырак», – дигән сүзләрен искә төшерде (Әт-Табәри, «Җәмигъ Әл-Бәйан»). Сәгъләбә ахырга кадәр үзенең бәхетсезлеккә төшүен бәхет дип санады. Ул мәңгелек бәхетне байлыкка һәм вакытлыча дөнья тормышындагы уңышка алыштырды.

Сәгъләбә кыйссасы безне Аллаһының ризалыгына каршы килмәүгә генә түгел, ә Аңа дога белән ни рәвешле мөрәҗәгать итәргә кирәклеген дә өйрәтә. Кеше Раббысыннан алырга теләгән әйбернең аның өчен яхшымы-юкмы булуы хакында күбрәк сорарга, яхшы булуына инанганнан соң гына догасында нык торырга тиеш. Югыйсә, сораган әйберендә мәшәкатьләр һәм бәла-казалар куркынычы булуы бар.

**Әхмәт хәзрәт Фәйзуллин,**
«Иман нуры» мәчетенең икенче имамы

**Татарстан Республикасы Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты тәкъдим иткән «365 көн догада» исемле китапта тормыш-көнкүрешебезгә, гамәл-гыйбадәтләребезгә кагылышлы булган һ.б. догалар урын алган. Газетабызның әлеге санында табигать күренешләре белән бәйле булган очракларда кылына торган догалар бирелде. Кадерле укучыларыбыз! Әлеге догалар сезнең өчен файдалы булыр дигән теләктә калабыз.**

## ЯҢГЫР ЯУГАНДА УКЫЛА ТОРГАН ДОГАЛАР

**1. «Аллааһүммә сәкйән һәнии-ән вә сыыйбән нәәфиган. Аллааһүммәҗгалһү сыыйбә рахмәтин вә ләә тәҗгалһү сыыйбә гаҙәәб».**

**Мәгънәсе:** *«Йә, Аллаһым, бу яңгырны безнең өчен рәхәт һәм файдалы ит. Йә, Раббым, бу яңгырны рәхмәт яңгыры кыл, газап яңгыры кылма».*

**2. «Аллааһүммә саййибән нәәфиган».**

**Мәгънәсе:** *«Йә, Аллаһым, файдалы яңгыр булсын!»*

**3. «Аллааһүммә иннии әгууҙү бикә мин шәрриһәә».**

**Мәгънәсе:** *«Йә, Аллаһым, дөреслектә, шушы яңгыр китерә алырлык зыяннан мин Сиңа сыенам!»*

## ЯҢА ТУГАН АЙНЫ КҮРГӘЧ УКЫЛА ТОРГАН ДОГА



Фото: unsplash.com

Тальхә бине Гобәйдулла радыяллаһу ганһедән килгән риваятьтәгечә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм яңа туган айны күргәч, болай дип дога кыла торган булган:

**«Аллааһүммә әһилләһүү галәйнәә бил-йүмни вәл-имәәни вәссәләәмәти вәл-исләәм. Раббии вә раббүкәллааһ».**

**Мәгънәсе:** *«Йә, Аллаһым, бу айны безгә бәхетле һәм бәрәкәтле ай ит. Иман, сәламәтлек һәм Ислам белән туп-тулы матур кичәләрдә тусын! Синең дә, вә минем дә Раббыбыз – Аллаһыдыр!»*

Яңа туган айны күргәндә түбәндәге доганы да укырга була:

**«Аллааһү әкбәр** (3 мәртәбә). **Аллааһүммә әһлилһү галәйнәә бил-әмни вәл-иимәәни вәс-сәләәмәти вәл-исләәм. Аллааһүммә-җгалһү ләнәә һиләәлә хайрин вә рушд».**

**Мәгънәсе:** *«Аллаһы Тәгалә һәрнәрсәдән олуграк. Йә, Аллаһым, бу айны безгә иминлек һәм иман, сәламәтлек һәм мөселманлык белән тудыр. Шулай ук аны безгә изгелек һәм тугрылык ае итеп кыл».*

## ҖИЛ-ДАВЫЛ ЧЫККАНДА УКЫЛА ТОРГАН ДОГА

**«Аллааһүммә иннии әс-әлүкә хайра һәҙиһир-риихи вә хайра мәә фииһәә вә хайра мәә әрсәлтә биһи вә нәгүуҙү бикә мин шәрри мәә фииһәә вә мин шәрри мәә әрсәлтә».**

**Мәгънәсе:** *«Йә, Аллаһым, Синнән бу җил-давылның хәерен телим. Аллаһым! Бу давыл белән җибәргән нәрсәнең хәерен Синнән телим һәм Син җибәргән нәрсәләрнең начарлыгыннан Сиңа сыенамын».*

## КҮК КҮКРӘГӘНДӘ ҺӘМ ЯШЕН ЯШЬНӘГӘНДӘ УКЫЛА ТОРГАН ДОГА

**«Аллааһүммә ләә тәкътүлнәә бигадабикә вә ләә түһликнәә бигаҙәәбикә вә гаафинәә бирахмәтик».**

**Мәгънәсе:** *«Йә, Аллаһым, безне ачуың һәм газабың белән һәлак итмә, рәхмәтең белән безгә исәнлек-саулык бир».*

## ҺӘРВАКЫТ ҺӘМ ҺӘР УРЫНДА УКЫРГА МӨМКИН БУЛГАН ДОГА

**«Әлхәмдүлилләәһи галәә күлли хәәлин фәиннәһү мүхәввилүләхвәәл. Раббәнәә әәтинәә фиддүнйәә хәсәнәтән вә фил-әәхырати хәсәнәтән вә кыйнәә гаҙәәбән-нәәр. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиин».**

**Мәгънәсе:** *«Һәр хәл өчен Аллаһы Тәгаләне мактыйбыз, чөнки хәлләрне үзгәртүче Ул. Йә, Раббым, безгә дөньяда да, Ахирәттә дә изге хәлләрне насыйп ит. Шулай ук безне җәһәннәм газабыннан сакла, Әй, Рәхмәтле Аллаһы, бөтен нәрсә Синең рәхмәтеңдә».*

**«365 көн догада»** китабыннан

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 05 (334) май, 2023 | шәүвәл-зөлкагъдә, 1444

# «МИНЕ АЛЛАҺЫ КИЧЕРМӘС» ДИП ӘЙТҮ – ГӨНАҺМЫ?

Хөрмәтле җәмәгать, безнең яшәешебез Аллаһының рәхмәте белән бара. Һәрбер сулышыбыз Аллаһы әмере белән, Аның безгә карата рәхимле, рәхмәтле булуы белән бәйле. Дөньяның гаять матурлыгы, барлык нигъмәтләрнең булуы Аллаһының рәхмәтедер. Шулай ук динебез дә безгә карата Аллаһының рәхмәте ул. Аллаһы Тәгалә безне хаклыкны аңлап, иман китереп, изге гамәлләр кылып, югары әхлаклы булып яшәүгә, дөнья һәм Ахирәттә бәхетле булуга чакыра. Коръән укый башлаганда да Аллаһының Рәхимле һәм Шәфкатьле дигән бөек исемнәре белән башлыйбыз.

Бервакыт Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең сәхабәләре белән сөйләшеп утырганда алар яныннан баласын күтәреп бер хатын үтеп китә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләреннән: «Бу хатын үз баласын утка ташлый алыр идеме?» – дип сорый. Алар: «Юк, Аллаһы Тәгалә белән ант итәбез, бу хатын мондый эшне эшли алмас иде», – дип җавап бирә. Шуннан соң Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ә Аллаһы Тәгалә Үз колларына карата, бу хатын үз баласын кызгануга караганда да, рәхимлерәк», – дип әйтә.

Һичшиксез, бу бик күркәм аңлату! Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте, Аңа гына хас рәвештә, чиксез һәм киңдер.

### ӨМЕТ ӨЗҮ – ШАЙТАННАН

Кайвакытта: «Мин күп гөнаһлар кылдым, Аллаһы кичермәс инде», яки билгеле бер кеше турында: «Ул кеше бик гөнаһлы, Аллаһы аны ничек кичерсен инде, нәрсә эшләсә дә, файдасы булмас», – дигән сүзләр ишетергә туры килә. Җәмәгать! Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән, кичерүеннән өмет өзү – шайтаннан, чөнки шайтанның гына өмете юк, ә безгә, җаныбыз тәнебездә вакытта, Аллаһының рәхмәтен өмет итеп, гафу итүен сорауда, тәүбәдә булу кирәк.

Шунысы да бик мөһим: башкаларга да Аллаһының рәхмәт ишекләрен ябарга хакыбыз юк. Нинди генә гөнаһ кылган булсалар да, иң беренче, Раббыбызның рәхмәтенә этәрү, аларга рәхимле булу сорала. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә, бик катгый итеп: «Бәндәләргә рәхимле булмаучыга рәхимлелек булмас», – дигән.

### «БАРЫСЫН ДА ГАФУ ИТӘМ»

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм хакында шундый бер риваять бар: көннәрдән бер көнне ул сәхабәләр белән утырганда кисәк кенә сүзен бүлеп: «Борылып карагыз әле, хәзер артыгыздан җәннәт кешесе үтеп китәр», – дигән. Сәхабәләр борылып караса, Мәдинәдә яшәүче берәү узып бара икән. Икенче көнне бу хәл тагын кабатланган. Өч көн шулай дәвам иткән. Бер сәхабә бу хәлгә бик аптыраган. Хикмәтне белү өчен, хәйлә табып, өч көнгә шул кешенең өенә кергән. Ул шул кешенең гаиләсе белән көн дә иртән торган, ашаган, эчкән, йоклаган. Өченче төнне хуҗага хәйләсен чишкән: «Расүлебез өч көн рәттән синең хакта «җәннәт кешесе» дип әйтте. Нинди изгелегең бар икән дип, хәйлә табып, синең өеңә кердем. Моның өчен мине кичер, гафу ит. Бездән артык намаз укымыйсың, бездән артык изгелегең дә юк шикелле. Нинди гамәлең өчен Аллаһы сине исән чакта ук җәннәт белән куандыра?» – дип сораган. Йорт хуҗасы: «Белмим. Син күргәнчә, намаз укыйм, нәфел уразалары тотам, калганы миңа мәгълүм түгел», – дигән. Теге кеше саубуллашып чыгуга таба кузгалгач, йорт хуҗасы аны туктатып, чакырып керткән һәм: «Намаз уку, ураза тотудан тыш, тагын бер гадәтем бар: һәр кичне йокларга ятар алдыннан, башны мендәргә куйганчы, Аллаһы Тәгаләгә ялварам: «Бүген яки, гомумән, мине рәнҗеткән, миңа карата хаксызлык кылган кеше булса, барысын да гафу итәм. Минем аркамда аларны җәһәннәм белән газаплама», – дип әйтәм», – дигән. Бу сүзне Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә җиткергәннәр. Ул: «Бу кеше киң күңелле булып, кешеләрне гафу итә белгән өчен, Кыямәт көнендә Аллаһы аның гөнаһларын кичерер», – дигән.

Димәк, кешеләрне кичерә, гафу итә белү киң күңелле, юмарт булуны күрсәтә. Икенчедән, башкаларны гафу итү – үзебезнең хата-кимчелекләрнең Аллаһы Тәгалә каршында кичерелүенә бер сәбәп булып тора. Без шуны белергә тиеш: нинди генә хаталарыбыз, гөнаһларыбыз булса да, Аллаһы Тәгалә кичерә.

### КИЧЕРӘ БЕЛИК!

Шайтанның максаты – безне Аллаһының рәхмәтеннән ваз кичтерү, өметебезне өзү. Шуңа күрә шайтанга ярдәмче булмыйк, Аллаһының яраткан бәндәсе булыйк. Якыныбыз, кардәшебез безгә карата нинди дә бер авырлык китерсә дә, гөнаһ эшләсә дә – кичерә белик. Тормышта туганнар, кардәшләр арасында, гаиләдә кичерә алмау сәбәпле туганлык җепләре өзелүен, гаиләләр таркалуын, кардәшлек беткәнен күрергә туры килә. Асылда боларга җиткергән сәбәпләр бик гади яки кечкенә булып, үзебезнең кичерә алмавыбыздан киләдер. Кичерү Аллаһы Тәгаләнең олуг сыйфаты булып, бездә дә бу сыйфатның чагылышы булырга тиеш.

Әй, кардәшләрем, уйланыйк. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтләре чиксез. Аллаһы Тәгалә безнең онытылучан булуыбызга, гөнаһлар кылуыбызга карамастан, безгә Үзенең рәхмәтен вәгъдә итә.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә:

***«Әйт: «Ий үз-үзләренә каршы зарарда булган колларым! Аллаһының рәхмәтеннән өметегезне өзмәгез, чөнки Аллаһы** [ширектән тыш] **барлык гөнаһларны да ярлыкый!» Һичшиксез, Ул –** [гөнаһларны күпләп] **Гафу итүче, Рәхимле».***

*«Әз-Зүмәр / Төркемнәр», 39:53*

Без – Адәм балалары, хаталанабыз, ялгышабыз, әмма вакытында хатабызны аңлап, Аллаһыга кайтып гафу сорасак, Аллаһы Кичерүче, Ярлыкаучы, Рәхимле, Шәфкатьле Зат. Аллаһының рәхмәтеннән өметебезне өзмик.

**Инсаф хәзрәт Ибатуллин,**
«Динислам» мәчете имам-хатыйбы




Фото: unsplash.com

# Самолетта намаз ничек укыла?

**СОРАУ:**
**Әссәләмү галәйкүм! Самолетта намаз ничек укыла?**

**ҖАВАП:** Вә галәйкүм әссәләм! Самолет җиргә утырганда намаз вакыты әле чыкмаган булса, намаз самолеттан төшкәч укыла.

Әгәр самолетта очу вакытында намаз вакытлары керә икән, намазны, борт хезмәткәрләре белән сөйләшеп, кыйблага карап, басып укырга тырышырга кирәк. Мондый намаз дөрес була һәм аны каза кылуның кирәге калмый.

Самолет хезмәткәрләре басып укырга рөхсәт бирмәсә, намазны (идәнгә – ред.) утырган килеш укырга, ә сәҗдәләрен тулысынча башкарырга кирәк.

Әгәр болай да уку мөмкинлеге юк икән, намаз креслода утырган килеш укыла, рөкүгъ, сәҗдәләр ярым бөгелеп кенә башкарыла. Бу рәвешле укылган намазны самолеттан төшкәч кабаттан укырга кирәк булачак – намазның дөрес булмау куркынычы бар, чөнки кыям намазның рөкеннәреннән санала, ягъни мәҗбүри өлеше. Ә намазның рөкеннәрен бары авырган кешегә генә калдырырга ярый. Башка вакытта намазны бөтен шартларын саклап укырга кирәк.

## Гипслы вакытта тәһарәт алу

**СОРАУ:**
**Әссәләмү галәйкүм! Әгәр кешенең битенә гипс салынган булса, хәнәфи мәзһәбе буенча тәһарәтне ничек алырга?**

**ҖАВАП:** Вә галәйкүм әссәләм! Гипс булган очракта юеш кул белән гипснең күбрәк өлешен сөртеп алырга кирәк, аннары калган әгъзаларны кабул ителгән тәртиптә юуны дәвам итәргә.

Имам Шурунбуләли «Нур Әл-Идах»та болай дип яза:

«Әгәр кеше хиҗәмә ясаткан, яраланган яисә аяк-кулларын сындырган һәм шул сәбәпле тән әгъзаларын юып булмаслык итеп бәйләвеч кулланган икән, шул бәйләвечнең күбрәк өлешен сөртеп алу тиешле була».

Бу кагыйдә гипслы вакытта госел алуга да кагыла.

Ә Аллаһы яхшырак белүче!

## Мәченең селәгәе нәҗесме?

**СОРАУ:**
**Әссәләмү галәйкүм! Белүемчә, ерткыч хайваннарның селәгәе, нәҗесе – авыр нәҗесләрдән. Мәче дә ерткыч хайваннар төренә карый бит, димәк, аның дә селәгәе нәҗес була? Ә өйдә мәче тоту ярый, диләр. Аңлатыгыз әле.**

**ҖАВАП:** Вә галәйкүм әссәләм! Мәче – ерткыч хайван, димәк, аның селәгәе нәҗес санала, әмма хәнәфи мәзһәбендә шундый кагыйдә бар: теге яки бу мәсьәлә буенча карар чыгарганда, ачык дәлил – аять, хәдис яисә сәхабәләрнең фәтвасы булганда, мантыйк (логика) һәм кыяс (аналогия) исәпкә алынмый.

Бу очракта галимнәребез Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең түбәндәге хәдисенә таяналар:

«Ул (мәче) – нәҗес түгел, ул бит сезнең белән бергә яши» (Әт-Тирмизи, Әхмәд һ.б.).

Үзенең «Әл-Мәбсут» хезмәтендә имам Әс-Сәрахси бу хәдисне түбәндәгечә шәрехли:

«Ул (хәдис) – сәбәпкә (мәченең чиста хайван булуына) ишарә».

Шулай итеп, мәче, аның селәгәе, йоны чиста санала. Бары тик мәче эчкән суны гына тәһарәт өчен куллану ярамый, чөнки мәче чиста булмаган ризык ашаган булырга мөмкин.

Ә Аллаһы яхшырак белүче!

**dumrt.ru**
сайтыннан алынды

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 05 (334) май, 2023 | шәүвәл-зөлкагъдә, 1444






# ИЗГЕ БОЛГАР ҖЫЕНЫНДА УНИКАЛЬ ЭКСПОЗИЦИЯ ТӘКЪДИМ ИТЕЛДЕ

**Изге Болгар җыенында катнашучылар һәм кунаклар Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм аның сәхабәләренең ядкәрләре экспозициясен карады.**

Зөлкагъдә аеның 1нче көнендә (21нче майда), Шәһре Болгарда Истәлек билгесе бинасында Изге Болгар җыенында катнашучыларга һәм кунакларга Мөхәммәд пәйгамбәр һәм аның сәхабәләренең 10 ядкәреннән торган уникаль экспозиция тәкъдим ителде. Күргәзмә ТР Рәисе Рөстәм Миңнеханов ярдәмендә оештырылды.

Истәлек билгесендә урын алган кыйммәтле әйберләр арасында – пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең чәче, май касәсе һәм кылычы, сәхабә Билял радыяллаһу ганһе, Пәйгамбәрнең хатыны Гайшә радыяллаһу ганһә һәм кызы Фатыйма радыяллаһу ганһә чүлмәкләре, шулай ук аның кул тегермәне, Халид бине Әл-Вәлид радыяллаһу ганһе сәфәрләрдә йөртә торган фляжкасы һәм көбәсе, Әбү Бәкер Әс-Сиддыйк радыяллаһу ганһе пычагы, Кәгъбәтуллаһның Кара ташы бар.

Күргәзмә Татарстан һәм Идел буе төбәкләре мөселманнары арасында зур кызыксыну уятты. Рәсми ачылышка кадәр үк ишек янында күргәзмәгә керергә теләүчеләрнең зур чираты җыелды. Күргәзмәгә керүчеләр экспозицияне берничә тапкыр карап узды, ядкәрләрне Татарстанга алып килүче Дагыстан кардәшләребез Коръәннән аятьләр һәм салаватлар укыды.

Махсус күргәзмә Дагыстан Республикасыннан беренче тапкыр китерелде. Кыйммәтле ядкәрләрне Дагыстан мөфтие урынбасары Мөхәммәдрасул хаҗи Саадуев җитәкчелегендәге Дагыстан Республикасы делегациясе озата бара. Татарстанга ядкәрләр махсус сейфларда китерелде.

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте җитәкчелеге Дагыстан мөфтие Әхмәт хаҗи Абдулаевка Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен рәсми кабул итү көне уңаеннан Татарстан мөселманнары өчен кыйммәтле бүләк ясавы өчен рәхмәтен белдерә.

2005 елдан Болгар җыены Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте һәм Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы ярдәме белән үткәрелә. 2022 елда Болгарда Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы уңаеннан төп бәйрәм тантанасы узды.

Бу вакыйганың мөһим тарихи әһәмиятен исәпкә алып, «Татарстан Республикасының бәйрәм һәм истәлекле көннәре турында «Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 14 нче октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән Идел буе Болгар дәүләте тарафыннан рәсми рәвештә Ислам динен кабул итү көне Татарстан Республикасының истәлекле датасы буларак билгеләнгән.

**dumrt.ru** сайтыннан






















Фотолар dumrt.ru сайтыннан алынды

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 05 (334) май, 2023 | шәүвәл-зөлкагъдә, 1444

# ГОМУМИ ӘДӘПЛӘР



Фото: shutterstock.com

**Хөрмәтле укучыларыбыз! Сезнең игътибарыгызга газетабызның алдагы саннарында олуг имам Әбү Хәмид Әл-Газалинең «Әдәпләр» китабында урын алган, әдәп-әхлак тәртипләренә кагылышлы булган нәсыйхәтләрне биреп бардык. Газетабызның әлеге санында имам Әбү Хәмид Әл-Газали тапшырган кайбер гомуми әдәпләр урын алды. Аллаһы Тәгалә аларны үтәп, әлеге әдәп-әхлак кагыйдәләрен тормышыбызга кертеп җибәрүне һәм Үзенең ризалыгына ирешүләребезне насыйп әйләсә иде.**

Бер хикмәт иясе әйткән булган: «Бу син үтәргә тиешле кайбер әдәпләрнең бер өлеше:

Үзеңнең дусларыңнан, дошманнарыңнан да һәрчак канәгать бул, алар алдында беркайчан да түбәнсенмә һәм бервакытта да алардан курыкма. Җитди бул, ләкин тәкәббер булма. Һәрнәрсәдә «алтын урталык»ны сакла. Йөргән вакытта як-ягыңа каранма. Бер төркем кешеләрне күргәч, алар янына туктама. Утырганда туры утыр. Бармакларыңны кысма, балдагың белән уйнама. Тешләреңне һәм борыныңны казыма. Йөзеңнән чебен кума. Киерелмә һәм иснәмә. Тыныч кына утыр. Аңлаешлы итеп сөйлә. Синең белән сөйләшүчеләрнең яхшы сүзләрен игътибар белән тыңла.

Шул ук вакытта үзеңнең дулкынлануыңны да, битарафлыгыңны да белдермә. Сөйләүченең сүзләрен кабатлавын сорама. Шаяруларга игътибар итмә. Малай булсынмы ул, кызмы, аны ошатуыңны беркемгә дә әйтмә. Хатын-кызлар кебек алтын-көмешләр такма, шул ук вакытта коллар кебек үзеңнең тышкы кыяфәтеңә карата игътибарсыз да булма.

Һәрнәрсәдә тәртип сакла. Сөрмәне кирәгеннән артык кулланма, майларны да артык күп майлама. Кыйссалар сөйләү теләгендә нык торма. Чит кешегә түгел, хәтта балаларың һәм хатыныңа да үзеңнең матди хәлең хакында сөйләмә. Әгәр алар синең фәкыйрьлегең хакында белеп алсалар, алар каршында дәрәҗәң төшәр. Әгәр байлыгыңның күп булуы хакында белеп алсалар, синнән тагын да күбрәкне таләп итәрләр. Аларны ярат һәм аларга карата каты күңелле булма. Аларга карата мәрхәмәтле бул, шул ук вакытта үзеңнең йомшак ягыңны да аларга күрсәтмә.

Әгәр кемне дә булса гаепләргә җыенсаң, ашыкма һәм дәлилләреңне ныклап тикшер. Кулларың белән артык күп хәрәкәтләр ясама. Тезләнмә. Ачуың беткәч кенә сөйләш.

Әгәр ил башлыгы белән дус булырга туры килсә, аның белән артык якынайма һәм көннәрдән бер көнне ул синең дошманың булып китмәс дип ышанма. Аңа карата балаларга карата булган кебек йомшак һәм ягымлы бул. Үзен ишетергә теләгәннәрне аңа да әйт. Әгәр ул синең фикереңә колак салса, һичкайчан аның үзе, гаиләсе, балалары һәм якыннары арасында киртә булма.

Синең янга бары тик яхшы вакытта гына килә торган дуслардан ерак бул, чөнки мондый кешеләр дошман хисапланыр.

Байлыкны үзеңнең дәрәҗәңнән өстен куйма.

Кешеләр алдында төкеренмә, чөнки җәмәгать алдында бу бер дә күркәм гадәт түгел.

Иптәшеңә үзеңнең проблемаларың хакында сөйләмә, чөнки, синең аска тәгәрәвеңне күрү белән, ул синең дошманыңа әйләнәчәк.

Акыллы кешеләр белән шаярма, югыйсә, алар сине дошман күрүе бар. Надан кешеләр белән шаярма, алар сиңа дорфа җавап кайтарырлар. Шаярулар кешенең дәрәҗәсен төшерә, түбәнсетә, оят хисе югалуга китерә, кайгыга сала һәм ярату хисен юкка чыгара. Калебне һәлак итә. Раббыңнан ерагайта, гаепләүгә урын калдыра, яхшы хатирәләрне юк итә, гөнаһларны арттыра һәм тәнкыйть ителүгә һәм хата-кимчелекләрдән көлүгә сәбәп була».

Без Аллаһы Тәгаләдән безне туры юлга күндерүен сорыйбыз. Йә Раббым! Безне һидаятьтә булучылардан кыл, сәламәтлекләребезне арттыр һәм сәламәт булучылардан кыл. Аллаһым, башкаларны саклаган һәм яклаган кебек, безне дә Үзеңнең яклавың һәм саклавың астына ал! Йә Раббым! Безгә биргән нигъмәтләреңне безнең өчен хәерле кыл, безнең тәкъдиребезгә язылган кайгы-хәсрәттән безне Үзең сакла! Аллаһы Тәгаләдән башка Ул язганнардан азат итүче һәм коткаручы юк! Аның дошманнары беркайчан да өстенлеккә ирешмәячәк! Шулай ук Ул Үзенә дус итеп сайлаганнар беркайчан да түбән дәрәҗәгә төшмәс!

Безнең Раббыбыз бөек һәм барча мактауларга лаек! Аннан гына истигъфар сорыйбыз, гөнаһларыбыз өчен Аның алдында гына тәүбә итәбез. Аның сөекле пәйгамбәре Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аңа ияргән һәм хакыйкатьне җиткерергә ярдәм иткән тугры сәхабәләренә барча сәламнәребез булсын!

Барча мактаулар Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә генә! Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Аның сәламе һәм бәрәкәте булса иде! Әәмин.

**Имам Әбү Хәмид Әл-Газалинең**
«Әдәпләр» китабыннан

# ЗӘЙСӘН – ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ЮГАЛГАН ТАРИХЫ

Инкыйлабка кадәрге булган татар чыганакларында шәһәр Кызылъяр атамасы белән билгеле. Әмма соңрак, сәүдә эшләре белән бәйле рәвештә, кешеләр Казахстанның калган шәһәрләренә, шул исәптән Зәйсәнгә дә килеп урнаша.

Зәйсән – Кытай чикләреннән ерак булмаган җирдә, Казахстанның көнчыгышында урнашкан зур булмаган шәһәр ул. Шәһәр кызыклы тарихка ия. Аның үсеше һәм алга китешенә төрле этник төркемнәр үз өлешен керткән. Шул төркемнәрнең берсе – Зәйсән тарихында мөһим роль уйнаучылар булып, татарлар тора.

Татарлар Зәйсәндә регионның киңәюе чорында – XIX гасыр азагында төпләнә башлый. Ул вакытта Зәйсән кечкенә шәһәр була һәм Россия империясе белән сәүдә һәм транспорт үзәге ролен үти. Татарларларны икътисади мөмкинлекләр җәлеп итә.

Зәйсәндә татарлар төрле һөнәрләр һәм кәсеп: шул исәптән кул эше, сәүдә һәм җир эшкәртү эшләре белән шөгыльләнә. Алар шәһәрдә үз җәмәгатьчелекләренә нигез сала, биредә татар мәчете, ир-атлар һәм хатын-кызлар өчен татар мәктәпләре барлыкка килә. Аларның барысы да җирле татарлар өчен мәдәни һәм иҗтимагый тормышның үзәге булып тора.

Мәдәният һәм белем алу планында татарлар казах гаиләренә зур йогынты ясый. Алар да балаларын бу мәктәпләрдә укыта башлый, ә үзләре татар телен, гореф-гадәтләрен үзләштерә, шул рәвешле, татар милләтенең бер өлешенә әйләнә. Бу Зәйсән халкының инкыйлабка кадәрге сакланып калган фотоларында ачыктан-ачык күренә.

Зәйсәндә ике мәчет булган: берсе – казах, икенчесе татар мәчете. Алардан бары тик татар мәчетенең бинасы гына сакланып калган. Зәйсәндәге татар мәчете 1908 елда төзелгән тарихи мәчет. Хәзерге тарихи чыганакларда мәчет терлек белән эш итүче җирле сәүдәгәр Үлкин кажы Бикшәнтәев заказы буенча төзелгән диелгән. Ә төзелеш өчен кирпечләр Әхмәдзәки Әхтәмовның кирпеч заводында әзерләнгән.

Әмма мәчетне тикшерүче В.Кумарова һәм җирле төбәкне өйрәнүчеләр мәчет һәм шулай ук ир-атлар һәм хатын-кызлар мәктәпләре татар сәүдәгәре Әхмәдзәки Әхтәмовның (1865–1937) чыгымнарына төзелгән дигән фикерне раслый.

Әхмәдзәки хәзрәт Казан губерниясендәге Спас өязенең Яңа Баллыкүл авылыннан булган. Аның әтисе Әхтәм бине Бичәнтәй Тәтеш өязенең Чатбаш авылында мулла вазифасын башкарган. Әхмәдзәки хәзрәт Казанның танылган Апанай мәдрәсәсен тәмамлаган.

Әхмәдзәки хәзрәт 1889 елда Уфада Ырынбур мөселман Диния нәзарәте җыелышында имтихан тапшыра һәм имам-хатыйб һәм мөдәррис вазифасын үтәү хокукын ала.

1891 елдан Әхмәдзәки Әхтәмов Зәйсәндә дини вазифаларны башкарган: 1891–1895 елларда җирле хәрби мөселманнар арасында имам,



Әхмәдзәки хәзрәт Әхтәмов.
Фотоның чыганагы: wikipedia.org

ә соңрак ахун булып торган. Бу чорда ул үз эшен башлап җибәргән – шәхси кирпеч заводына нигез салган.

Зәйсән шәһәре татар җәмәгатьчелеге тормышына кагылышлы кызыклы мәгълүматларны Әхмәдзәки хәзрәтнең улы – Ягъкуб Әхтәмовның «Язмыш һөҗүмнәренә каршы» («Наперекор ударам судьбы») исемле китабыннан укып белергә мөмкин.

Совет чорында Зәйсән татарлары алдына үзләренең мәдәни үзенчәлекләре һәм гореф-гадәтләре проблемалары килеп баса. Совет хөкүмәте көчләп руслаштыру сәясәтен алып бара. Бу сәясәт Зәйсән татарларына шактый зур тәэсир ясый. Моңа карамастан, Зәйсән татарлары үзләренең мәдәни гореф-гадәтләрен һәм үзенчәлекләрен саклауны дәвам иткән.

Бүген татарлар Зәйсәннең мөһим мәдәни һәм этник күптөрлелегенең өлеше булып кала бирә. Әйе, еллар үтү белән халык саны кимесә дә, ләкин аларның шәһәр тарихы һәм мәдәниятенә керткән өлеше элеккегечә сизелә. Татар халкы бүген дә шәһәрнең бай мәдәни мирасының бер өлеше булып тора.

Соңгы елларда Зәйсәндә татар мәдәнияте һәм тарихына кызыксыну артты, шулай ук татар гореф-гадәтләренә һәм телгә багышланган мәдәни чаралар һәм фестивальләр дә оештырылап тора.

**Дамир Гайнетдинов язмасы,**
islam-today.ru сайтыннан тәрҗемә



Фото: silkadv.com

Зәйсәндә сакланып калган татар мәчете бинасы.



Фото: shutterstock.com

# Кешенең гаҗәеп табигате

Шәкыйкъ бине Ибраһим болай дигән: «Кешеләр минем белән сүздә дүрт нәрсәдә ризалаштылар һәм дүрт нәрсәдә гамәл белән каршы килделәр. Беренчесе, алар: «Без Аллаһы коллары», – дип әйттеләр, ә үзләре азат кешеләрнең гамәлләрен кыла торган булды. Икенчесе: «Безне Аллаһы тәэмин итә», – диделәр. Чынлыкта, күңелләре бары тик дөньяда булган әйбер белән генә тынычлык таба. Өченчесе: «Дөреслектә, Ахирәт дөньядан изгерәк», – диделәр, әмма үзләре дөнья өчен мал җыялар. Дүртенчесе: «Безгә үлемнән чара юк», – диделәр, үзләре «үлмибез» дигән кавемнең гамәлләрен кыла».

Әбү Зәррдән риваять ителә: «Өч нәрсә мине гаҗәпләндерде, хәтта көлдерде. Янә өч нәрсә мине кайгыртты, хәтта елатты. Мине көлдергән өч нәрсәнең беренчесе: үлем турында уйламаучы, дөньяга зур өмет баглаучы кеше. Икенчесе: эшеннән гафил булучы кеше, әмма аның эшеннән Аллаһы гафил түгелдер. Өченчесе: күп көлүче кеше, ләкин үзе Аллаһы аңа ачулымы яки разыймы икәнен белмидер.

Мине елаткан нәрсәләрнең беренчесе: дусларның аерылуы, ягъни Пәйгамбәребезнең һәм сәхабәләрнең үлүе. Икенчесе: үлемнең килүе. Өченчесе: Аллаһы каршына баскач, минем белән нәрсә буласын белмәү, ягъни җәннәткә яки җәһәннәмгә эләгәсемне белмәү».

# Җәннәт нидән яратылды?

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән риваять ителә. Ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән: «Җәннәт нидән яратылды?» – дип сораган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Судан», – дип җавап биргән. Без: «Җәннәт бинасы хакында хәбәр бир», – дидек. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтте: «Бер кирпече алтыннан, бер кирпече көмештәндер. Ул җәннәтнең балчыгы хуш исле яфәрдән барлыкка китерелгән, туфрагы – шафран, ягъни ризыкка төс бирә торган тәмләткечтән, вак ташлары – энҗе һәм якут ташыдыр. Ул җәннәткә кергән кеше нигъмәтләнер һәм курыкмас, анда мәңге калыр – үлмәс, аның киемнәре искермәс, яшьлеге фани булмас».

Моннан соң Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Өч кешенең догасын Аллаһы Тәгалә кабул кылыр. Болар – гадел патша, ураза тотучының ифтар вакытында кылган догасы, золым кылынган кешенең догасыдыр, чөнки ул золым кылынган кешенең догасы болыттан югары күтәрелер, ул догага Аллаһы карар һәм: «Әй золым кылынган бәндәм, Үземнең олуглыгым белән ант итәм, әлбәттә, соңрак булса да, сиңа ярдәмемне бирермен»,– дип әйтер.

# Җәннәт әһеленең сыйфатлары

Гыйкримә болай дип әйткән: «Җәннәт әһеленең ирләре дә, хатыннары да утыз өч яшьлек кебек, буйлары аталары Адәм галәйһиссәламнең буе кебек – алтмыш аршын, сакалсыз, мыексыз егетләрдер, күзләре сөрмәле. Алар өчен җитмеш кием булыр, һәрбер киемнең төсе һәр сәгатьтә җитмеш төскә үзгәрер. Үзләренең йөзләрен аның йөзендә, ягъни үзенең хатыны йөзендә, күкрәгендә һәм хатынның балтырында күрерләр. Ул хатын йөзен иренең йөзендә, күкрәгендә һәм балтырында күрер. Җәннәттә алар төкермәсләр, сеңгермәсләр һәм ул җәннәт кешесе рәнҗүдән, моннан өстен булганнардан ерактыр».

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Өммәтемнең җәннәткә керүчеләренең беренче төркеме ундүртенче кичтәге ай төсендә булыр, ә алардан соң ук керүчеләрнең төсе иң якты йолдыз кебек булыр. Моннан соң аларга урыннар бирелер. Анда алар бәвелләнмәсләр, бәдрәфкә бармаслар, ягъни йомышларын үтәмәсләр, төкермәсләр һәм какырмаслар. Аларның тараклары алтындыр, аларның хуш ис чыгару өчен булган күмер савытлары үлүвәтдер (пыскып янганда хуш ис чыгара торган агач төре), ягъни гуд агачыдыр. Аларның тирләре яфәрдер һәм аларның яратылышлары бер ирнең яратылышы кебектер, буйлары аталары Адәм галәйһиссәламнеке кебек, алтмыш аршын булыр».

**«Тәнбиһүл гафилин»** китабыннан

# ӘНИЕМ ДӘРЕСЛӘРЕ

Мөмкинлек булган саен, ата-ана баласын үз әти-әнисе янына җибәрә. «Бала баласы балдан татлы», диелә бит халык мәкалендә дә. Әбиләренең дә шатлыклары эченә сыймый, кош тоткандай очып кына йөриләр, чөнки алар да оныкларын сагынып көтеп тора. Һәм башлана... Тәмледән-тәмле ризык белән сыйлаулар, йокысы туйганчы йоклатулар, ул торганчы абына-сөртенә вак-төякне эшләп бетерүләр... Оныкка нәрсәдер эшләтергәме соң?! Хәер, оныгы да эшлим дип атлыгып тормый, уянуга, җиң сызганып, телефонына ябыша. Чүп утыйсы юк, утын кисәсе юк, су да ташыйсы юк. Һәрбер йортта диярлек, суның кайнары-салкыны краннан агып тора, юынтык суны да чыгарып түгәсе юк – торбадан үзе агып чыгып китә, Аллаһыга шөкер!

Шулай да, эшлим дигән кешегә эш буа буарлык: идән-сәке юу, тәрәзә пыялаларын чистарту, ишегалды себерү, рәшәткә тотkaларын рәтләп-нығытып кую, буяп-матурлап җибәрү, дисеңме... Кош-корт, казлар һәм үрдәкләргә кычыткан, әрекмән җыю, җим туглау, бәрәңге әрчү, кибеткә бару – болар барысы да вак-төяк кебек. Әмма олыгаеп барган, аяклары авырткан әбинең һәр атлаган адымы исәптә. Әйтеп эшләтүгә караганда, бала үзе белеп эшли башласа, бу инде зур бәхет. Әмма андый бәхет күктән төшми шул. Барысы да тәртип-тәрбиягә бәйле. Ә аның өчен баланың үз әти-әнисе дә кечкенәдән – 3 яшеннән 7 яшенә кадәр өендә эш тәртибен күреп, гаилә кагыйдәләрен үзләштереп, ата-анасына булышып үскән булуы кирәк. Үз балаларына да белгәннәрен өйрәтсәләр, бу, һичшиксез, чын бәхет була инде. «Тотрыклы нәсел» менә шулай бара.

Ә бүген без, олылар, ни эшлибез? «Әйдә, йокласын! Барыбер, минемчә эшләми бит ул. Әкрен генә үзем эшләп бетерермен әле»,– дип уйлыйбыз. Менә шулай уйлавыбыз – безнең хата. Безне әбиләр, әниләр карап торып, янәшәләренә бастырып эшләткәннәр. Ошамаса, яңадан эшләткәннәр. Бер юган идәнне кабат юып кара әле син?! Ә инде сәке, карават, өстәл асларын «онытып» калдырсаң, өч мәртәбә да юасың. Менә бу – чын тормыш мәктәбе: әби кеше кечкенә оныгы үз гомерендә онытмаслык, киләчәктә балаларына гына түгел, ә үзенең оныгына да дәрес итеп тапшырырлык итә, миенә сеңдерә һәм максатына ирешә!

Ә без балаларыбызны һәм оныкларыбызны сукыр мәхәббәт белән яратабыз, үзебез дә аңламыйча, рухи яктан гарипләндерәбез. Алар үсеп җитеп, ата ялкауга әйләнгәч, аптырашка калабыз: «Нишләп болай килеп чыкты соң? Шулкадәр тәрбияләдек, җил-яңгыр тидермәдек, эшләтмәдек, какмадык-сукмадык, тыймадык, үзенчә яшәттек. Ә шулай да без теләгәнчә булмады»... Әгәр ул бала, мал абзарындагы тиресне түксә, бакчадагы бәрәңге чүбен утаса, маңгай тирен агызып печәнен чапса, аны киптереп өйсә, телефонда уйнап утырырга вакыты да, теләге дә калмас иде. «Әти-әнигә, әби-бабайга хәлемнән килгәнчә ярдәм иттердең, рәхмәт Сиңа Аллаһы Тәгаләм», – дип, догасын да кылыр иде әле. Менә бу тәрбия чын татарча, мөселманча булыр иде.

Боларны укыгач, бәлки «юк, барыбер, үзебезчә эшлибез, борынгы ысуллар бүгенге көнгә батмый», дип уйлаучылар да булыр.

Авызың бер пешсә, салкын суны да өреп эчәсең. Тәрбия мәсьәләсендә дә шулай. Тиешле вакытны кулдан ычкындырсаң, соңга каласың: тал чыбыгы тирәккә әйләнгән, ныгыган була...

Кайсы гына чорда яшәсәк тә, бала – ата-анасы өчен кадерле, газиз, ул аның өчен җанын да кызганмый. Борынгылар бу яратуны яшерә белгән. Алар газизләрен үзләренә сиздерми генә, эчке ярату белән яратып гомер иткән. Баланы артык яратуның тиешле нәтиҗә бирмәячәген, «мин-минлек»кә китерәчәген яхшы белгәннәр. Шуңа да, гасырлар буена исбатланган хезмәт тәрбиясен кулланганнар. Ялкаулыкның – шайтанны сөендерә, кешене түбәнгә тәгәрәтә, бәхетсезлеккә илтә торган гамәл икәнен аңлап, ничек кенә булса да, ата-ана үз баласын бәхетле итәргә тырышкан. Үзенең һөнәрен өйрәткән, фәнни һәм дини мәгълүмат бирергә омтылган, укыткан, вәгазен сөйләгән. Үзе белмәсә, белгән кеше янына илткән. Баласының надан калуыннан, эгоист, усал холыклы, мәрхәмәтсез булып үсүеннән уттан курыккан кебек курыккан. Ул заманнарда әдәпсезлек, тәртипсезлек, мәрхәмәтсезлек зур оят саналган. Шуңа да кеше үз нәселенең «яман аты» чыгудан курыккан.

Үз тормышымнан кечкенә генә бер мисал китерәм. Без үскәндә, урамга чыгар алдыннан, әниебез апаларыма булавкалар биреп: «Балалар, урамда җил булып, күлмәк итәкләрегезне ачып оятка калмагыз, игътибарлырак булыгыз», – дияр иде.

Безнең әти-әни, әби-бабайларыбыз тәрбиянең иң үтемлесен – вәгазь сөйләүне кулланган. Эш арасында да, бала колагы ишетерлек, йөрәгенә үтеп керерлек итеп, җай белән генә гел сөйләп торган. Нәрсәне шулкадәр ятлатасы, сеңдерәсе килгән соң аларның?

Иң элек, максат куелган. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Һәр эшнең нәтиҗәсе нияттән тора», – дип әйтеп калдырган. Борынгылар ислам дине кагыйдәләрен белеп кенә калмаган, тормышта бик уңышлы файдалана, куллана да белгән. Баласына биргән белем-тәрбиясен хәдисләр белән ныгытып барган.

Бу урында әниемнең таләпләреннән кайберләренә тукталып үтәм.

Берәр җиргә барасы булсак, кат-кат кисәтә иде ул:

– яман холыклы балалардан ерак булыгыз, чөнки яман холык йогышлы була;

– күңелне каралтырлык әдәпсез сүзләр сөйләмәгез, кычкырышмагыз, сүз көрәштермәгез, иптәшләрегезнең хәтере калырлык ишарәләрдән, бигрәк тә, аларга кул күтәрүдән сакланыгыз;

– дусларыгызда булган әйбергә кызыкмагыз, алардан ул нәрсәне сорамагыз; бөеклек – алуда түгел, бирүдәдер;

– кирәкмәгән, файдасыз нәрсәләр эшләп, дәресләрегезгә соңга калмагыз...

*(Дәвамы киләсе санда)*

**Сәйдә абыстай Аппакованың**
«Тузмас бүләк» китабыннан

# Сөннәтче бабай


Фото: shutterstock.com

*(Дәвамы. Башы алдагы санда)*

Ул, шундагы сандык өстенә утырып, бик озак дога кылырга тотынды. Аның карт йөзеннән мөлдер-мөлдер яшь агарга тотынды. Ул бик озак дога кылып: «Ярабби, карчыгымны гафу ит, гөнаһларыны кичер!» – дип, йөзен сыйпады. Шуның берлән ул үзенең күз яшьләрен дә тәмамларга теләсә дә, яшьләр туктамады. Ул, аның үлүенә ышанмаган кеби, өйнең бөтен җирләрене карап бетерде; бер кемне дә [күрә] алмады. Бакчасына чыкты. Анда да бер әсәр-галәмәт күрмәде.

Ул, шуларның һәммәсенә ышанып, өенә кереп утырырга өлгермәде, ишекнең тышкы ягында әллә нәрсә тырмаша башлады. Ул: «Гөлйөзем әбинең рухы килде», – дип куркып китеп, ишекне ачты. Үзләренең соры мәчеләре килеп керде. Ул, «мәү, мәү!» дип, әле анда барып, әле монда килеп, әллә нәрсә эзләп йөри башлады. Бик озак маташканның соңында ул Сөннәтче бабайның янына килде дә, күзенә карап: «Мәү-ү!» – диде. Сөннәтче бабай мәченең шул кычкыруында аерым ачык: «Әби кайда?» – дигән сүзне аңлады. Сөннәтче бабайның каткан күзеннән тагы яшь агарга тотынды. Ул мәче берлән сөйләшергә тотынды:

– Әбиең үлде, үлде. Оҗмахка китте, дога кыл, – диде.

Мәче, әллә нәрсә аңлаган кеби, тагы: «Мәү-ү!» – диде.

Сөннәтче бабайга карчыгы төсе — шул мәче бик якын кеби тоелды. Ул аның савытына сөт салды. Ләкин мәче, берәр генә кабып караса да, ашамады.

Сөннәтче бабай мәченең дә кайгырганыны күреп, шуннан котылыр өчен, йортка чыкты. Аның күзенә, берсе артлы берсе тезелеп, ана үрдәкнең командасы астында менеп килә торган үрдәкләр күренде. Ул, аларны ашатыр өчен, анларга әбиләре үлгәнен белдермәс өчен, өйалдыннан ярма алып чыгып сипмәкче булды. Моны күргәч үрдәкләр тагы: «Бак, бак!..» – диярргә тотындылар. Сөннәтче бабай боларның бакылдауларында да: «Әби кайда?» – дигән сүзне аңлады. Шул уйдан котылыр өчен ул капка төбенә таба чыгарга өлгермәде, хәзрәтнең угылы килеп, аны чәй эчәргә чакырып алып китте.

Анда да бербуйдан Гөлйөзем әби сөйләнсә дә, остазбикәнең тәмле чәен эчеп, татлы ашларын ашап, Сөннәтче бабай азрак күңелен юатты.

Ул, икенде намазын укып, өенә кайтты. Зур мөгезле карт кәҗә аны кычкырып каршы алды. Ул аның мөгез арасын кашыды, аны сөйде. Ләкин кәҗә, җилененә сөт тутырып кайтканга: «Савыңыз!» – дип, әбисенә кычкыра башлады. Сөннәтче бабай тагы чыдый алмады: тагы күзеннән яшь акты. Менә күрше килене килеп, кәҗәне саварга тотынды. Кәҗә, саудырмаска теләмәсә дә, бик ямьсез тавыш берлән: «Минем сөтемне урлыйлар, минем сөтемне талыйлар, әби, кил!» – дигән кеби, кычкыруыннан туктамады.

Сөннәтче бабай ахшам намазына барыр өчен тәһарәт алырга комган эзләргә тотынды. Комганның җирендә булмавы тагы аның исенә карчыгыны төшерде. Ястүгә кадәр ул ялгыз Коръән укып, дога кылып үткәрде. Ястү намазын укып, гомерендә җәймәгән урынын үзе җәеп ятты. Ләкин түшәк, ястык аңар ят күренде; ул урын каты тоелды. Өе, шул Сөннәтче бабай өйләнгәннән бирле торган өе, үзенеке түгел, кешенеке кеби сизелде. Ул, белгән бөтен догаларын укып, йокларга теләде. Тагы янында карчыгы юклыгы аны уятты. Ул бик озак уйлады; үзенең яшьлегеннән алып бүгенге көнгә кадәр уйлады. Көн буе йөреп арыган тән аруына бар аруы да катышты. Ул йокыга китә башлады. Менә кәҗә кычкырды. Аның кычкыруында бабай тагы әбине сагынуын аңлады. Тагы йокы качты; тагы уйлар, тагы кайгылар...

Менә таң якынлашты. Сөннәтче бабай йокыга киттеме-юкмы, ансы мәгълүм түгел — ул ап-ак күлмәктән, көлеп кенә, Гөлйөзем әбинең: «Карт, намаздан каласың!» – дигән тавышын ишетте, төсен күрде. Ул, сикереп торып: «Әлхәмделилла, әһле җәннәттән икән», – дип, ян-янга карарга тотынды. Чынын да намаз вакыты бик җиткәнен сизеп, торып, тәһарәт алып, намазга китте. Намаздан соң хәзрәткә төшен сөйләде. Хәзрәт:

– Оҗмах әһеленнән икән, – дип, тагы бабайны кәефләндерде.

Ләкин өйгә кайткач, ул тагы ялгызлык хис итте, тагы аны шул киң, зур өй кыса, изә башлады. Ул, өендә утыра алмаенча, капка төбендә, күршеләр янында бакчада тора башлады. Кич берлән һаман ялгыз йокларга өйрәнмәде. Шул ялгызлыкның изүенә хәйлә таба алмады.

* * *

Бер төнне Сөннәтче бабай, әллә нинди ямьсез төшләр күреп, уянып китте. Бөтен тәненең туңганын күреп, юрганына тагы бөтереленебрәк ятты. Ләкин ни кылынса да аркасын җылыта алмады. Ул әйләнде-бәйләнде, урынын төзәтте, ләкин аркасы җылынмады. Әүвәле йокыга киткән кеби булды, тагы аркасы туңып уянды. Тагы калыкты, тагы уянды. Менә аркасының туңганын белеп, ярты йокы, ярты уяу көенчә: «Карчык, карчык!.. Арканы җылыт!» – диде. Үзенең тавышын үзе ишетеп, уянып китте. Шул тавыштан куркып, йокысы качты. Тагы күңеленә Гөлйөзем әбинең үлүе, аның, мәрхүм, һәрвакыт Сөннәтче бабайның аркасын җылытып йоклатуы исенә төште. Шул рәхәт көннәрне исенә төшереп, аның аркасы тагы туңа башлады. Ул тагы Гөлйөзем әби хакында уйларга тотынды. Уйлый-уйлый, ничектер, «тагы өйләнергә» дигән фикер башына килеп керде. Элгәре ул шул фикерне башыннан ташламакчы булса да, ләкин уй, бизгәк кеби, аны ташламады...

*(Дәвамы киләсе санда)*

**Гаяз Исхакый**

## ДҮШӘМБЕ

**07.00** «Минбар» 12+
**07.25** «Хәерле сәгатьтә» 12+
**08.20, 17.00** «Онлайн мәдрәсә» 12+
**08.40, 17.30** «Хаҗ кылырга өйрәник» 12+
**08.55, 17.45** «1001 хәзинә» 6+
**09.10, 18.00** «Тәфсир». Тимергали Юлдашев 12+
**09.35, 18.25** «Фикер» 12+
**10.20, 19.15** «Әлифба. Коръән уку сабаклары» 12+
**10.45, 19.40** «Коръән могҗизалары» 12+
**11.00, 19.55** «Дин турында» 12+
**11.30, 20.30** «Хикмәтле хикәяләр» 12+
**11.40, 20.40** «Намазга өйрәник» (хатын-кызлар өчен) 12+
**12.00** Азан 12+
**12.05, 21.00** «Чудеса сотворения» 12+
**12.20, 21.15** «Хузур Вояж с Антоном Кротовым» 12+
**12.35, 21.30** «Онлайн медресе» 12+
**13.10, 22.05** «Знамения Корана в свете современной науки» 12+
**13.25, 22.20** «Узнаем у имама» 12+
**14.10** «Разговоры о важном» 12+
**14.15, 23.05** «Алифба» 12+
**14.35** «Есть вопрос – есть хадис» 12+
**15.00, 23.25** Документальные фильмы 12+
**15.35** «Тайна» 12+
**15.55** «Халяль-лайфстайл» 12+
**16.15** «Рухуль Байан» 12+
**16.20** «Ислам сегодня» 12+
**00.55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод 0+

## СИШӘМБЕ

**07.00** «Минбар» 12+
**07.35** «Хәерле сәгатьтә» 12+
**08.30, 17.25** «Җан авазы» 12+
**08.45, 17.40** «Хаҗ кылырга өйрәник»12+
**09.00, 17.50** «Рисәлә» 12+
**09.15, 18.05** «Сабыйлар остаханәсе» 6+
**09.35, 18.25** «Рухел Бәйан» 12+
**09.45, 18.35** «Татарлар тарихы» 12+
**10.30, 19.25** «Тәмле булсын» 12+
**10.50, 19.45** «Имамнан сорыйк» 12+
**11.40, 20.40** «Намазга өйрәник» (ир-атлар өчен) 12+
**12.00** Азан 12+
**12.05, 21.00** «Азбука Ислама» 6+
**12.30, 21.25** «Онлайн медресе» 12+
**13.05, 22.00** «Дети в саду пророчества» 12+
**13.25, 22.20** «40 хадисов – 40 толкований» 12+
**14.00, 22.55** «Узнаем у имама» 12+
**14.45, 23.40** «Халид бин Валид» 12+
**15.40** «Познай свою религию» 12+
**16.00** «Ислам сегодня» 12+
**16.40, 00.35** «Поучительные истории» 12+
**16.45, 00.40** «Хафтияк Шариф» 6+
**17.00** «Мәслихәт» 12+
**20.35** «Гыйбрәтле хикәяләр» 12+
**00.55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод 0+

## ЧӘРШӘМБЕ

**07.00** «Минбар» 12+
**07.25** «Хәерле сәгатьтә» 12+
**08.20, 17.00** «Онлайн мәдрәсә» 12+
**08.40, 17.30** «Хаҗ кылырга өйрәник» 12+
**08.55, 17.45** «1001 хәзинә» 6+
**09.10, 18.00** «Тәфсир». Тимергали Юлдашев 12+
**09.35, 18.25** «Бәрәкәтле гаилә» 12+
**10.20, 19.15** «Әлифба. Коръән уку сабаклары» 12+
**10.45, 19.40** «Коръән могҗизалары» 12+
**11.00, 19.55** «Дин турында» 12+
**11.30, 20.30** «Хикмәтле хикәяләр» 12+
**11.40** «Намазга өйрәник» (хатын-кызлар өчен) 12+
**12.00** Азан 12+
**12.05, 21.00** «Вера в предопределение» 12+
**12.15, 21.10** «Хузур Вояж с Антоном Кротовым» 12+
**12.30, 21.25** «Онлайн медресе» 12+
**12.55** «40 хадисов – 40 толкований» 12+
**13.30, 22.05** «Узнаем у имама» 12+
**14.20, 21.50** «Знамения Корана в свете современной науки» 12+
**14.35** «Есть вопрос – есть хадис» 12+
**15.00, 23.20** Документальные фильмы 12+
**15.35, 23.55** «Тайна» 12+
**15.55, 00.15** «Голос разума» 12+
**16.30, 00.50** «Рухуль Байан» 12+
**16.35** «История ислама в России» 12+
**20.40** «Намазга өйрәник» (ир-атлар өчен) 12+
**22.55** «Есть вопрос – есть хадис» 12+
**00.55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод 0+

## ПӘНҖЕШӘМБЕ

**07.00** «Минбар» 12+
**07.25** «Хәерле сәгатьтә» 12+
**08.20, 17.00, 17.00** «Онлайн мәдрәсә» 12+
**08.40, 17.30** «Хаҗ кылырга өйрәник» 12+
**08.55, 17.45** «1001 хәзинә» 6+
**09.10, 18.00** «Тәфсир». Тимергали Юлдашев 12+
**09.35, 18.25** «Фикер» 12+
**10.20, 19.15** «Әлифба. Коръән уку сабаклары» 12+
**10.45, 19.40** «Коръән могҗизалары» 12+
**11.00, 19.55** «Дин турында» 12+
**11.30, 20.30** «Хикмәтле хикәяләр» 12+
**11.40, 20.40** «Намазга өйрәник» (хатын-кызлар өчен) 12+
**12.00** Азан 12+
**12.05, 21.00** «Чудеса сотворения» 12+
**12.20, 21.15** «Хузур Вояж с Антоном Кротовым» 12+
**12.35, 21.30** «Онлайн медресе» 12+
**13.10, 22.05** «Знамения Корана в свете современной науки» 12+
**13.25, 22.20** «Узнаем у имама» 12+
**14.10** «Разговоры о важном» 12+
**14.15, 23.05** «Алифба» 12+
**14.35** «Есть вопрос – есть хадис» 12+
**15.00, 23.25** Документальные фильмы 12+
**15.35** «Тайна» 12+
**15.55** «Халяль-лайфстайл» 12+
**16.15** «Рухуль Байан» 12+
**16.20** «Ислам сегодня» 12+
**00.55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод 0+

## ҖОМГА

**07.00** «Минбар» 12+
**07.35** «Хәерле сәгатьтә» 12+
**08.30, 17.25** «Җан авазы» 12+
**08.45, 17.40** «Хаҗ кылырга өйрәник» 12+
**09.00, 17.50** «Рисәлә» 12+
**09.15, 18.05** «Сабыйлар остаханәсе» 6+
**09.35, 18.25** «Рухел Бәйан» 12+
**09.45, 18.35** «Татарлар тарихы» 12+
**10.30, 19.25** «Тәмле булсын» 12+
**10.50, 19.45** «Имамнан сорыйк» 12+
**11.40, 20.40** «Намазга өйрәник» (ир-атлар өчен) 12+
**12.00** Азан 12+
**12.05, 21.00** «Азбука Ислама» 6+
**12.30, 21.25** «Онлайн медресе» 12+
**13.05, 22.00** «Дети в саду пророчества» 12+
**13.25, 22.20** «40 хадисов – 40 толкований» 12+
**14.00, 22.55** «Узнаем у имама» 12+
**14.45, 23.40** «Халид бин Валид» 12+
**15.40** «Познай свою религию» 12+
**16.00** «Ислам сегодня» 12+
**16.40, 00.35** «Поучительные истории» 12+
**16.45, 00.20** «Хафтияк Шариф» 12+
**17.00** «Мәслихәт» 12+
**20.35** «Гыйбрәтле хикәяләр» 12+
**00.55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод 0+

## ШИМБӘ

**07.00** «Минбар» 12+
**07.25** «Хәерле сәгатьтә» 12+
**08.20, 17.00** «Онлайн мәдрәсә» 12+
**08.40, 17.30** «Хаҗ кылырга өйрәник» 12+
**08.55, 17.45** «1001 хәзинә» 6+
**09.10, 18.00** «Тәфсир». Тимергали Юлдашев 12+
**09.35, 18.25** «Бәрәкәтле гаилә» 12+
**10.20, 19.15** «Әлифба. Коръән уку сабаклары» 12+
**10.45, 19.40** «Коръән могҗизалары» 12+
**11.00, 19.55** «Дин турында» 12+
**11.30, 20.30** «Хикмәтле хикәяләр» 12+
**11.40** «Намазга өйрәник» (хатын-кызлар өчен) 12+
**12.00** Азан 12+
**12.05, 21.00** «Вера в предопределение» 12+
**12.15, 21.10** «Хузур Вояж с Антоном Кротовым» 12+
**12.30, 21.25** «Онлайн медресе» 12+
**12.55** «40 хадисов – 40 толкований» 12+
**13.30, 22.05** «Узнаем у имама» 12+
**14.20, 21.50** «Знамения Корана в свете современной науки» 12+
**14.35** «Есть вопрос – есть хадис» 12+
**15.00, 23.20** Документальные фильмы 12+
**15.35, 23.55** «Тайна» 12+
**15.55, 00.15** «Голос разума» 12+
**16.30, 00.50** «Рухуль Байан» 12+
**16.35** «История ислама в России» 12+
**20.40** «Намазга өйрәник» (ир-атлар өчен) 12+
**22.55** «Есть вопрос – есть хадис» 12+
**00.55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод 0+

## ЯКШӘМБЕ

**07.00** «Минбар» 12+
**07.35, 17.25** «Шифа» 12+
**08.10, 18.00** «Фикер» 12+
**09.00, 18.50** «Дин турында» 12+
**09.35, 19.20** «Мәслихәт» 12+
**10.00, 19.45** «Әхлак сабаклары» 12+
**10.10, 19.55** «Балам-багалмам» 12+
**10.35** «Имамнан сорыйк» 12+
**11.25** Фильм: «Шиһабетдин Мәрҗани» 12+
**12.00** Азан 12+
**12.05** «Онлайн медресе» 12+
**12.30, 21.25** «Хузур Вояж с Антоном Кротовым» 12+
**12.45, 21.40** «Минбар. Истории» 12+
**13.15, 22.10** «Ислам сегодня» 12+
**13.55, 22.50** «Познай свою религию» 12+
**14.15, 23.10** «Узнаем у имама» 12+
**15.00, 23.55** Документальные фильмы 12+
**15.35, 00.30** «Медицина Пророка»
**16.00** Короткометражный фильм 12+
**16.25** «40 хадисов – 40 толкований» 12+
**17.00** «Онлайн мәдрәсә» 12+
**20.20** Фильм: «ТР МДН – 30 ел» 12+
**20.50** «Мөнәҗәттә халкым моңы» 12+
**21.00** «Онлайн медресе» 12+
**00.55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод 0+


# ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**

Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе **Камил СӘМИГУЛЛИН;**

«Хозур» нәшрият йорты директоры **Ришат ХӘМИДУЛЛИН;**

ТР МДНнең Шәригать бүлеге җитәкчесе **Булат МӨБАРӘКОВ;**

Татарстанның баш казые **Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**

ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы **Габдулла ӘДҺӘМОВ**

Баш мөхәррир: **Хамматов Л. Г.**
Мөхәррирләр: **Юлдашева А. И., Ситдикова Г.Р.**
Логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Гарифуллин И. Ф.**
**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** izdat@huzur.ru

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**НӘШИР:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт).
Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.

Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.

Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә. Заказ № 2589.
График буенча – 22 нче май 21.00, гамәлдә – 21.00 сәгатьтә кул куелды.

Газетага ярты елга язылу бәясе – 168,90 сум.
Индексы – П4333. Чыгу көне: 24 нче май.
Казан шәһәренең мәчетләрендә 24 нче май көнне таратыла.

# НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

## ИЮНЬ 2023 / КАЗАН

| Көн | Көн исеме | ИРТӘНГЕ НАМАЗ | | Кояш чыга | ЗӘВӘЛ | ӨЙЛӘ НАМАЗЫ | ИКЕНДЕ НАМАЗЫ | АХШАМ НАМАЗЫ / ИФТАР | ЯСТУ НАМАЗЫ |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | | | | | | |
| 01 | Пәнҗ | 01:07 | 01:37 | 03:07 | 11:41 | 12:00 | 17:23 | 20:16 | 21:46 |
| 02 | Җом | 01:06 | 01:36 | 03:06 | 11:41 | 12:00 | 17:24 | 20:17 | 21:47 |
| 03 | Шим | 01:05 | 01:35 | 03:05 | 11:41 | 12:00 | 17:25 | 20:18 | 21:48 |
| 04 | Якш | 01:04 | 01:34 | 03:04 | 11:41 | 12:00 | 17:26 | 20:19 | 21:49 |
| 05 | Дүш | 01:03 | 01:33 | 03:03 | 11:41 | 12:00 | 17:26 | 20:21 | 21:51 |
| 06 | Сиш | 01:02 | 01:32 | 03:02 | 11:42 | 12:00 | 17:27 | 20:22 | 21:52 |
| 07 | Чәрш | 01:01 | 01:31 | 03:01 | 11:42 | 12:00 | 17:28 | 20:23 | 21:53 |
| 08 | Пәнҗ | 01:01 | 01:31 | 03:01 | 11:42 | 12:00 | 17:28 | 20:24 | 21:54 |
| 09 | Җом | 01:00 | 01:30 | 03:00 | 11:42 | 12:00 | 17:29 | 20:25 | 21:55 |
| 10 | Шим | 01:00 | 01:30 | 03:00 | 11:42 | 12:00 | 17:29 | 20:26 | 21:56 |
| 11 | Якш | 00:59 | 01:29 | 02:59 | 11:43 | 12:00 | 17:30 | 20:27 | 21:57 |
| 12 | Дүш | 00:59 | 01:29 | 02:59 | 11:43 | 12:00 | 17:30 | 20:27 | 21:57 |
| 13 | Сиш | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 11:43 | 12:00 | 17:31 | 20:28 | 21:58 |
| 14 | Чәрш | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 11:43 | 12:00 | 17:31 | 20:29 | 21:59 |
| 15 | Пәнҗ | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 11:43 | 12:00 | 17:32 | 20:30 | 22:00 |
| 16 | Җом | 00:57 | 01:27 | 02:57 | 11:44 | 12:00 | 17:32 | 20:30 | 22:00 |
| 17 | Шим | 00:57 | 01:27 | 02:57 | 11:44 | 12:00 | 17:32 | 20:31 | 22:01 |
| 18 | Якш | 00:57 | 01:27 | 02:57 | 11:44 | 12:00 | 17:33 | 20:31 | 22:01 |
| 19 | Дүш | 00:57 | 01:27 | 02:57 | 11:44 | 12:00 | 17:33 | 20:31 | 22:01 |
| 20 | Сиш | 00:57 | 01:27 | 02:57 | 11:45 | 12:00 | 17:33 | 20:32 | 22:02 |
| 21 | Чәрш | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 11:45 | 12:00 | 17:33 | 20:32 | 22:02 |
| 22 | Пәнҗ | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 11:45 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 23 | Җом | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 11:45 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 24 | Шим | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 11:45 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 25 | Якш | 00:59 | 01:29 | 02:59 | 11:46 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 26 | Дүш | 00:59 | 01:29 | 02:59 | 11:46 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 27 | Сиш | 01:00 | 01:30 | 03:00 | 11:46 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 28 | Чәрш | 01:00 | 01:30 | 03:00 | 11:46 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 29 | Пәнҗ | 01:01 | 01:31 | 03:01 | 11:46 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 30 | Җом | 01:02 | 01:32 | 03:02 | 11:47 | 12:00 | 17:34 | 20:31 | 22:01 |

28 июнь – Корбан гаете